| ГЛАВА<br>БАГАЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 октябрь, 2019 ел Багай ав. № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
Районының Багай авыл җирлегең Кулабердино авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 24 октябренә 12 сәг 00 минутка Кулабердино авылы, Үзәк урамы, 1 нче йорт янында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегең Кулабердино торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Багай авыл җирлеге Кулабердино торак пункт территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

-балалар мәйданчыкларын төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру::*

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һ Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Кузнецова